«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәре»муниципаль берәмлегендә гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәгә 15 нче кушымта

# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Нурлат шәһәрендә халык җыены нәтиҗәләре турында

11 декабрь 2021 ел № 6

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2021 елның 11 декабрендә 12 сәгать 00 минутта, 12 сәгать 30 минутта: «Сембер (йортларның так номерлары), Юданов, Әхмәтов, Андреев, Киямов, Виссарионов, Тихая, Чишмәле, Новостройки, Братская, Рябиновая, Дубравная, Ипподромная, Шоссейный, Бакиров, Семенов тыкрыкларындагы барлык йортлар урамнарында юынтык суларны агызып җибәрү челтәрләрен төзүгә әзерләнә торган проект-смета документларын һәм дәүләт экспертизасын әзерләү мәсьәләсе буенча этаплап узган гражданнар җыенының нәтиҗәләре турында беркетмә төзелде.

Тавыш бирү нәтиҗәләре:
«Риза» - 280 кеше
«Каршы» - 0 кеше

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:
Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашкан 538 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 280 кеше, бу 51% тәшкил итә.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
РИЗА" позициясе өчен гражданнар җыенында 278 катнашучы тавыш бирде; "КАРШЫ" позициясе өчен җыенда 0 кеше тавыш бирде, "Тавыш бирүдән тыелдым" позициясе өчен 2 кеше тавыш бирде.
Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Юго-Западный» микрорайонында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип таныргa.
2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Юго-Западный» микрорайоны территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче һәр балигъ булган кешедән 2022 елда үзара салым акчаларын 1000 сум күләмендә кертергә.
3. Әлеге акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

«Сембер (йортларның так номерлары), Юданов, Ахметоа, Андреев, Киямов, Виссарионов, Тихая, Чишмәле, Новостройки, Братская, Рябиновая, Дубравная, Ипподромная, Шоссейный, Бакиров, Семенов тыкрыкларындагы барлык йортлар урамнарында юынтык суларны агызып җибәрү челтәрләрен төзүгә әзерләнә торган проект-смета документларын һәм дәүләт экспертизасын әзерләү».

4. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүматының порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы ________________ __________С.Ф. Усманов.__________
(имза) (имзаны расшифровкалау)